**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның XXI утырышы
КАРАРЫ

«28 » февраль 2025 ел № 3 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
2024 елгы социаль-икътисадый үсеше
йомгаклары һәм 2025 елга бурычлары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә,
"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2024 елгы социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2025 елга бурычлары турында"гы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы А.Ә. Шәфигуллинның «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2024 елгы социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2025 елга бурычлары турында»гы хисабын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетына 2025 елның 15 мартына кадәр:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгы хисабында, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы икътисад министры, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутатлары чыгышларында әйтелгән кисәтүләрне һәм тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чаралары планын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Ютазы район Советына карауга тапшырырга;

-Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше планнарын уңышлы үтәүне тәэмин итәргә, аның максаты икътисадны тотрыклы, динамикалы үстерү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшәүчеләр өчен уңайлы мохит тудыру нигезендә халыкның тормыш сыйфатын күтәрү булырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл

һәм шәһәр җирлекләрен комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

- салым салу базасын булдыру, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре бюджетларына өстәмә финанс чаралары җәлеп итү эшчәнлеген җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча активлаштырырга;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләрендә халыкның тормыш дәрәҗәсен киметүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүләрдән бертигез дәрәҗәдә файдалануын тәэмин итү чараларын күрергә;

- торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы һәм тулаем Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләренең экологик иминлеген тәэмин итү чараларын дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар кабул ителгән мизгелдән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы –
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

**Хәерле көн, хөрмәтле Мидхәт Рафкатович!**

**Хөрмәтле депутатлар, кунаклар һәм җитәкчеләр!**

Бүген без Ютазы муниципаль районының 2024 елга социаль-икътисадый үсешенә йомгак ясыйбыз һәм 2025 елга бурычлар куябыз.

Махсус хәрби операция район администрациясе, оешмалары һәм учреждениеләре эшенә, халык тормышына үз төзәтмәләрен кертте. Безнең районда яшәүче ике йөздән артык кеше махсус хәрби операция барышында Ватаныбыз иминлеге һәм суверенитеты өчен фидакарьләрчә көрәшә. Ирекleләр булырга батырларча карар кылган якташларыбызга һәм хәрби бурычларны хәл итү өчен өлешчә мобилизация кысаларында антларына тугры калган барлык кешеләргә рәхмәт белдерәм.

Кызганычка каршы, югалтуларсыз булмый. Ватан өчен, киләчәк буыннарның тыныч тормышы өчен гомерләрен биргән батыр сугышчыларыбызны без һәрвакыт истә тотачакбыз.

Барлык һәлак булганнарны бер минутлык тынлык белән искә алуыгызны сорыйм. (Бер минут тынлык)

Рәхмәт. Утыруыгызны сорыйм.

Безнең сугышчылар Ватанны алгы сызыкта саклаган вакытта, төп бурыч – аларга якыннары өчен ышаныч һәм тынычлык тәэмин итү. 2022 елның сентябрендә үк районда мобилизацияләнгән гражданнарга ярдәм күрсәтү буенча волонтерлык штабы оештырылган иде. Бу вакыт эчендә волонтерлар тарафыннан гуманитар ярдәм, акча, медикаментлар җыю, кирәкле җиһазлар сатып алу һәм гуманитар йөкләр җибәрү буенча гаять зур эш башкарылды. Уртак көч белән 2024 елда район 25 тонна гуманитар йөк, 4 автомобиль, дүрт Альфа мотоциклы һәм бер квадроцикл җибәрде.

Авыл җирлекләрендә яшәүчеләр берләшеп маскировка ятьмәләре үрәләр, блиндаж шәмнәре ясыйлар, тушенка пешерәләр, өй токмачы, чәкчәк, печенье пешерәләр, яшь буынны уртак эшкә җәлеп итәләр. Бердәмлектә – безнең көч! Без ир-егетләребезгә булыштык һәм киләчәктә дә ярдәм итәчәкбез.

Без сугышчыларга гына түгел, аларның гаиләләренә, СВО ветераннарына да ярдәм күрсәтәбез. Безнең өчен бу эш өстенлекле. СВОда катнашучыларның гаиләләренә көнүзәк мәсьәләләрне хәл итүдә адреслы ярдәм күрсәтелде (түбәләрне ремонтлау, сууткәргечләр төзү, утын белән тәэмин итү, агачларны кисү һ.б.). Яңа ел алдыннан хәрбиләрнең балалары өчен яңа ел бүләкләре тапшыру, республика чыршысына бару чаралары оештырылды. Ел дәвамында мәдәният учреждениеләрендә СВОда катнашучыларның гаилә әгъзалары мәртәбәле кунаклар булып торган

чаралар уза. Муниципалитет дәрәҗәсендә хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә балалар бакчасына йөргән өчен ата-ана түләвеннән азат итүгә кагылышлы чаралар күрелде һәм районның гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы барлык балаларга бушлай кайнар ризык бирелә. Без һәлак булган якташларыбызны җирләү һәм кайтару чыгымнарын тулысынча түлибез. Әлеге максатларга җирле бюджеттан биш млн. сумнан артык акча бүленгән.

Башкарма комитеттан һәм авыл җирлекләре башлыкларыннан ир-егетләребезнең һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү мәсьәләсен аерым контрольдә тотуларын сорыйм!

Хөрмәтле утырышта катнашучылар!

Социаль бурычларны уңышлы хәл итү һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрү ныклы икътисадый нигез таләп итә.

Якынча мәгълүматларга караганда, 2024 елда тулай территориаль продукт 12 млрд. 3 млн. сум тәшкил итәчәк, ягъни чагыштырма бәяләрдә узган ел дәрәҗәсенә карата 103,8%.

Икътисад структурасында иң зур чагыштырма авырлыкны, бәяләүләр буенча, сәнәгать алып тора – 49% артык.

2024 елда сәнәгать җитештерүе индексы 2023 ел дәрәҗәсенә карата 104,2% тәшкил итте, төяп озатылган продукция күләме – 6 млрд.17 млн. сум, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 19% ка күбрәк.

Сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә иң зур өлешне «Электросоединитель» заводы алып тора. Товар продукциясе күләме 2,6 млрд. сумнан артык дип бәяләнә, бу 2023 ел дәрәҗәсеннән 36% ка югарырак.

«Әпсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты» ҖЧҖ 2024 ел йомгаклары буенча үз продукциясен җитештерү күләмнәрен 6% ка арттыра алды. Моңа Газпром структураларыннан заказларны яңарту, шулай ук тимер юл продукциясен җибәрү белән бәйле чыгымнарны киметү ярдәм итте (тимер юлдан китерүне заказчы үзе тәэмин итә башлады).

Төзелеш темпларының гомуми кимүе, төп ставканың үсүе фонында «Волма-Әбсәләм» төзелеш материаллары җитештерү предприятиесе җитештерү күләмен 15 проценттан артыкка киметкән.

Күрше Туймазы районы территориясендә өч яңа чыганак ачылу сәбәпле, Урыссу руда булмаган материаллар предприятиесендә инерт материаллар сату күләме кимегән.

Татарстан Республикасы Арбитраж суды 2023 елның августында Урыссу химия заводын банкрот дип таныды һәм аның мөлкәтенә карата конкурс производствосы кертелде. Бүген суд утырышлары дәвам итә. Предприятие кризистан сәламәтләндерү процедурасына чыгар дип өметләнәбез.

«Тапарт» ОЭМЗ агымдагы елның гыйнварыннан медицина җиһазлары исемлегенә керүче тренажерлар җитештерә башлады. Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган кешеләрне торгызу өчен предприятиедә эшләнгән тренажерлар белән тернәкләндерү комплексы нәкъ шушы көннәрдә Ютазы авылындагы амбулатория территориясендә урнаштырылган һәм кабул итә. Хәзерге вакытта предприятиенең иң югары йөкләнеше максималь бүлеп бирелгән куәтләргә якынлашты. Җитештерүне үстерү өчен өстәмә рәвештә 2 МВт электр энергиясе кирәк. Хөрмәтле Мидхәт Рәфкатович, бу мәсьәләдә ярдәм итүегезне сорыйм.

"Урыссу" сәнәгать паркы уңышлы эшләвен дәвам итә. Бүген биредә 22 резидент эшли. Компанияләр икътисадның төрле тармакларын тәкъдим итәләр. Территория 57% ка үзләштерелгән. 2024 елда оешмалар әйләнеше 1 млрд. 264 млн. сум тәшкил иткән, 2023 елның шул ук чоры белән чагыштырганда ул 36% ка арткан.

Сәнәгать паркының төп резиденты булып 2021 елда ачылган «Регионэлектро» ҖЧҖ комплектлы трансформатор подстанцияләре җитештерү заводы кала. Бер ел эчендә предприятие 190 млн. сумлык продукция озатты, күләмнәрен 1,8 тапкырга арттырды.

«Цемент трейд» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте цемент кабул итү һәм йөкләү өчен җир өсте һәм җир асты конструкцияләрен алыштырып, күчереп төяү пунктын реконструкцияләүне тәгәлләде, һәркайсы 300 тонна саклау өчен дүрт сыешлык урнаштырды. Бүгенге көндә ай саен 1,5 мең тоннага кадәр продукция кабул итә. Киләчәктә, күчереп төяү потенциалын кулланып, төзелеш конструкцияләре җитештерүне, тагын 1000 тонна сыешлык куюны планлаштыра.

Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды ярдәмендә «Унипарк» компаниясе хисап елында гомуми мәйданы 600 кв.метр булган ике җылытылган җитештерү бинасы төзеде. Бүген инде бу биналар резидентларга арендага бирелгән.

Районның икътисадый һәм социаль тормышында кече һәм урта бизнес аерым роль уйный. Тулай территориаль продукт күләмендә кече һәм урта бизнес өлеше бәяләү буенча 33,5% тәшкил итәчәк. 485 эшкуарлык субъекты теркәлгән. Кече һәм урта эшмәкәрлектә (КУЭ) эшләүчеләр саны ел башы белән чагыштырганда 20% тан артыкка арткан һәм 3057 кеше тәшкил иткән. Районда үзмәшгульләр саны - 1343, шуларның 87% ы актив.

КУЭ субъектларына ярдәм итү кысаларында ел дәвамында республика һәм федераль ярдәм чаралары, салым законнарындагы яңалыклар һәм эшмәкәрләрнең законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча булган мөмкинлекләр турында өйрәтү чаралары оештырылды.

Федераль һәм республика финанс һәм финанс булмаган ярдәм чараларыннан 142 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты файдаланган, аларның гомуми суммасы 113 млн сум.

Районда 140 сәүдә объекты бар, шул исәптән 38е авыл җирлегендә.

Стационар сәүдә объектлары булмаган 17 торак пунктта «Ютазы район кулланучылар кооперативы» кулланучылар җәмгыяте көче белән күчмә сәүдә оештырылган.

2024 елның 9 аенда ваклап сату әйләнеше ике млрд.сумнан артык тәшкил иткән. Җан башына ваклап сату әйләнеше буенча без республикада 26 нчы урында торабыз.

Электрон сәүдә үсеше нәтиҗәсендә эшкуарларның үз продукцияләрен районнан читтә сату мөмкинлеге барлыкка килде. 2024 елның октябрь башына 168 кеше товарларны маркетплейсларга урнаштырган. Район территориясендә 20дән артык электрон сәүдә бирү пункты бар, шул исәптән сигезе авыл җирлегендә.

Республика маркетинг үзәге ресурсларында хисап чорында 26 тәэмин итүче 145 млн. сум күләмендә табыш алган. Маркетинг үзәгенең сәүдә ресурсларыннан файдалану нәтиҗәләре буенча 2024 елда без 26 нчы урында торабыз.

Республика маркетинг үзәгенең һәм электрон сәүдә мәйданчыкларының потенциалын активрак файдаланырга кирәк.

2024 елның гыйнвар – сентябрь айларында төп капиталга инвестицияләр күләме 1 млрд 309 млн.сум тәшкил иткән, ягъни узган елның шушы чорына карата 101%.

Инвестиция эшчәнлеген үстерү өчен районда КУЭ субъектлары өчен кирәкле мәгълүматны үз эченә алган инвестиция паспорты булдырылды.

Район башлыгы каршында киңәшмә органы төзелде, аның төп функциясе инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга ярдәм итү мәсьәләләрен карау.

Районда инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда ярдәм итү һәм яңа инвесторлар җәлеп итү өчен инвестиция вәкаләтлесе билгеләнгән.

Хисап елында район халкының тормыш дәрәҗәсе һәм сыйфаты күрсәткечләренең уңай динамикасы сакланып калган.

Район предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүчеләрнең уртача исәпләнгән хезмәт хакы 2024 елның гыйнвар-ноябрь айларында 56 764,9 сум тәшкил итте һәм 2023 ел белән чагыштырганда 20% ка артты.

Хисап елының 9 аенда җан башына акча кереме шул ук чор белән чагыштырганда 16% ка арткан һәм 31 625 сум тәшкил иткән.

Эшсезлек буенча рекордлы түбән күрсәткечләр күрәбез. Эшсезлек дәрәҗәсе 0,10% тәшкил итә, 10 кеше эшсез булып санала һәм бу сан кими бара. Эш бирүчеләр тарафыннан 30дан артык вакантлы урын игълан ителгән. Хезмәт базарындагы киеренкелек икътисад үсеше өчен аеруча зур куркыныч булып тора, бигрәк тә эшче белгечлекләргә ихтыяҗ зур.

Агросәнәгать комплексы район икътисадының иң мөһим тармакларының берсе булып кала. 2024 ел авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре өчен авыр булды. Май башындагы кыраулар, яңгыр һәм боз рәвешендә озакка сузылган явым-төшем нәтиҗәсендә ашлыкның коелуы һәм тамырларда һәм тезмнәрдә шытып чыгуы уңышның шактый югалтуына китерде.

Бөртеклеләрнең тулаем җыемы – 37,6 мең тонна, уңдырышлылык - гектардан 20,3 центнер.

Районда 10560 баш эре мөгезле терлек исәпләнә (АППГ карата 95%), шул исәптән 3353 баш сыер (АППГ карата 98%). Баш санының кимүе кайбер крестьян-фермер хуҗалыклары ябылу һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга күчерелү белән бәйле.

2024 елда район хуҗалыкларында 18,9 мең тонна сөт җитештерелгән. 2023 ел белән чагыштырганда савым 11% ка арткан.

Республика ярдәме белән район 600 баш тана сатып алган. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановка аерым рәхмәт сүзләре җиткерәм. 268 баш кайтарылды, быел февральдән сентябрьгә кадәр тагын 332 баш кайтачак.

2024 елда акчалата табыш 1 млрд 274 млн. сум тәшкил итте, бу узган елның шушы чорына караганда 33% ка күбрәк, 1 хезмәткәргә 3 млн 886 мең сум, 2023 елга үсеш 43%, 1 гектар сөрү җиренә 34 мең сум, 2023 елга үсеш - 36%.

2024 ел йомгаклары буенча авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы бер хезмәткәргә 46 370 сум тәшкил итте (ТР 57 684 сум), шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2024 ел дәвамында районның авыл хуҗалыгы формированиеләрендә уртача айлык хезмәт хакы дәрәҗәсе уңай динамикага ия, үсеш 21% тәшкил итте (ТР 23%). «АгроМир» ҖЧҖ 51 мең сум үсеш алган, үсеш - 28 %, Тукай исемендәге ҖЧҖ - 50 мең сум, үсеш - 24%. Иң аз хезмәт хакы Нәбиуллин И.М. КФХ, «Таң» ҖЧҖ - 37әр мең сум.

Хисап елында авыл хуҗалыгына 192 млн. сум инвестиция җәлеп ителгән.

Вафауллин Ансель крестьян-фермер хуҗалыгында инвестпроектлар актив гамәлгә ашырыла.

Июль аенда биредә 1600 кв. метр мәйданлы ашлык склады файдалануга тапшырылды. Биологик куркынычсызлык буенча чараларны үтәү максатында дезинфекция барьеры һәм санитария үткәргече төзүне дәвам итә. Әлеге проектларга якынча унбиш миллион сум үз акчалары юнәлдерелгән.

«Гаилә фермаларын үстерү» грантын гамәлгә ашыру кысаларында 200 башка исәпләнгән бозаулар абзары төзү дәвам итә, 2025 елда 250 башка исәпләнгән сыер абзары төзүне планлаштыра. Кертемнәр 65 млн. 800 мең сум тәшкил итәчәк.

«Агро-Мир» ҖЧҖ үз көче белән смета бәясе 38 млн.сум булган 500 башка исәпләнгән бозау абзарын реконструкцияли. 2025 елның III кварталына файдалануга тапшыру планлаштырыла.

Тукай исемендәге ЖЧЖдә һәм Нәбиуллин Илдус Мәгъсүм улының крестьян-фермер хуҗалыгында сөтчелек комплекслары төзү дәвам итә. Объектлар төзелеше 2023 елда ук башланган иде, әмма җитештерелә торган продукциягә тотрыксыз бәяләр бу хуҗалыкларда объектларны файдалануга тапшыруга йогынты ясады.

Август ахырында «Дубравушка» балаларны савыктыру лагере һәм Вафауллин Ансель крестьян-фермер хуҗалыгы базасында машина белән сыер саву осталарының 51 нче республика конкурсы үткәрелде. Бу чара профессионалларны гына түгел, кунакларны, тармак белгечләрен дә җыйды. Конкурс агросәнәгать комплексы вәкилләре өчен чын бәйрәмгә, шулай ук тәҗрибә һәм идеяләр алмашу өчен мөһим мәйданчыкка әверелде.

Бюджет даирәсенең тулы канлы эшләвенә, барлык проектларны һәм программаларны нәтиҗәле гамәлгә ашыруга җирле бюджетның баланслылыгын тәэмин итү ярдәм итә. Үз салым һәм салым булмаган керемнәрнең үтәлеше төгәлләштерелгән еллык фаразга карата 108,5% тәшкил итте. Узган елның шушы чорына карата үсеш темпы 115,9% тәшкил итте. Районның берләштерелгән бюджетына 35 млн. сумнан артык өстәмә керем тупланган.

Җир ресурслары һәм муниципаль мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итү һәм эш итү бюджетны уңышлы тулыландыруның нигезе булып тора. Файдаланылмаган җир өлешләрен рәсмиләштерү эше дәвам итә, муниципаль милек хокукын тану турында судка дәгъва гаризалары җибәрелә.

Узган елны ил Президенты Владимир Владимирович Путин Гаилә елы дип игълан итте. Районда балигъ булмаган балалары булган 3000нән артык гаилә яши, шуларның 352се — күпбалалы, 86 бала тәрбиягә алган һәм опекун гаиләләрендә тәрбияләнә.

Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарыннан һәм опека бүлегеннән әлеге гаиләләрне даими контрольдә тотуын сорыйм.

Халкыбызның сәламәтлеге турында кайгырту мөһим юнәлеш булып кала. Районның сәламәтлек саклау системасын яңарту күп авырулардан үлүчеләр санын киметүгә турыдан-туры ярдәм итә. Районда үлем күрсәткече юл картасы буенча рөхсәт ителгән чик күрсәткечләрдән түбәнрәк.

2024 елда «Сәламәтлек саклау» милли проекты кысаларында Керәш Бүләк авылында фельдшер-акушерлык пункты файдалануга тапшырылды, район үзәк хастаханәсенең азык-төлек блогына капиталь ремонт ясалды.

Район хастаханәсе табиблар белән 90% ка, урта медицина персоналы белән 98% ка комплектланган.

Хөрмәтле депутатлар!

Мәгариф өлкәсе аерым игътибар үзәгендә кала. Ул районда бюджет акчаларын иң зур алучы. Хисап елында тармак үсешенә бюджетның чыгым өлешенең 65% ы юнәлдерелде.

Ел саен мәгариф объектларын капиталь ремонтлауга һәм төзүгә финанслауның барлык чыганаклары исәбеннән кимендә 100 млн. сум бүлеп бирелә, 2024 ел да искәрмә булмады - 1нче балалар бакчасына капиталь ремонт ясалды, «Үсеш ноктасы» программасы буенча Димтамак авылы мәктәбендә яңа үзәк төзелде, «Һәр баланың уңышы» федераль программасы буенча 3нче Урыссу мәктәбенең спорт залына ремонт ясалды, интернат-мәктәп территориясе төзекләндерелде.

Безнең районның мәгариф киңлегенә 14 гомуми белем бирү, 17 мәктәпкәчә белем бирү, бер өстәмә белем бирү учреждениесе һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен бер интернат-мәктәп керә.

Сыйфатлы белем алу һәм ерак торак пунктлардан укучыларның белем бирү учреждениеләренә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен 25 торак пункттан 376 бала китерелә. 2024 елда автопарк яңа автобус белән тулыланды.

Тугыз мәктәп санлы, гуманитар һәм табигый-фәнни профильле белем бирү үзәкләрен булдыру буенча «Үсеш ноктасы» федераль проектында катнаша. Бу эшнең төп маркеры булып дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре тора.

Бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре тотрыклы. 74 укучының 20се мәктәпне медальләр белән тәмамлады, шуларның 12се – алтын белән. Урыссу гимназиясен тәмамлаган Ковалева Виктория БДИда ике фәннән иң күп балл җыйган: Инглиз теле, укытучысы Иламова Зөлфия Нинелевна һәм әдәбият, укытучысы Зиннәтуллина Рамилә Хәлим кызы, Татарстан Республикасының иң яхшы укытучылары республика конкурсында җиңүче.

Мәктәп укучылары олимпиадалары йомгаклары буенча без республикада алдынгы позицияләрнең берсен билибез. Төбәк этабында 57 кеше җиңүче һәм призер булды, төбәкара олимпиадаларның дүртесе һәм халыкара олимпиадаларның өчесе призер булды.

Олимпиадаларда һәм ярышларда җиңүчеләрне, призерларны, шулай ук аларның остазларын ел саен яшь талантлар слетында башлык гранты белән бүләклибез. Премияләр суммасы бер миллион сумнан артык тәшкил итте.

Бер ел эчендә күп нәрсәләргә ирештек, әмма тынычланырга иртәрәк, рус теле, әдәбияты, физика буенча БДИ нәтиҗәләре республика күрсәткечләреннән түбәнрәк. Мәгариф бүлегенә һәм мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге фәннәр буенча укытуның сыйфатын яхшырту өчен эшне җайларга кирәк.

Район мәгариф учреждениеләре грантларда һәм конкурсларда актив катнаштылар. Кәрәкәшле балалар бакчасы һәм Ютазы мәктәбе «Балаларга туган телне өйрәтү буенча иң яхшы тәҗрибәләр» республика конкурсында җиңүчеләр булдылар. Алынган грантка интерактив һәм уен җиһазлары сатып

алганнар. 2 нче балалар бакчасы «Акыллы уеннар» уен комплектлары сатып алуга сертификатка ия булды.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның сыйфатлы һәм һәркем файдалана алырлык белем алу хокукын гамәлгә ашыру максатында ел ахырында район үзәгенең 6 нчы балалар бакчасында аутистик спектры бозылган балалар өчен төркем эшли башлады.

Бүген ике мәгариф учреждениесе - Ютазы авылындагы база мәктәбе һәм районда бердәнбер «Балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү учреждениесе биналарын капиталь ремонтлау иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып кала. Алар 1950-1958 елларда төзелгән. Идән япмалары һәм ишекләр алыштыруны таләп итә, диварлар ремонтка мохтаҗ, инженерлык коммуникацияләре яраксыз хәлгә килгән *(мәктәп – 176,4 млн.сум, ЦДТ – 158,6 млн. сум, нәтиҗәдә -335,0 млн. сум)*. Хөрмәтле Мидхәт Рәфкатович, әлеге мәсьәләне хәл итүдә ярдәм итүегезне сорыйм.

Киләчәк буыннарны тәрбияләүдә Россиянең «Алдынгылар хәрәкәте» балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең аерым роле барлыкка килергә тиеш.

Безнең районда барлык 14 мәктәптә дә, ике балалар бакчасында да башлангыч бүлекләр булдырылды һәм 2024 елдан ике пилот китапханә эшли башлады. "Олимп" спорт мәктәбендә, "Атлант" яшьләр клубында, балалар иҗаты үзәгендә беренчел бүлекләр ачылды. Шуның нәтиҗәсендә 1150 бала кызыклы һәм файдалы эшчәнлек белән мавыктырылды һәм аларның саны арта бара. Безнең өчен мөһим бурыч — хәрәкәт эшенә социаль яктан зәгыйфь категориядәге балаларны, авыр тормыш хәлендә булганнарны, ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны кертү.

2022 елдан районда ишегалды лагере эшли. Бу уңышлы практикаларның берсе, анда 14-17 яшьлек балигъ булмаганнар лагерьга вожатыйлар сыйфатында эшкә урнаша. Ишегалды лагерьлары өч сменада эшли. 2024 елда 15 яшүсмер эшкә урнаштырылган, җәйге чорда 200дән артык бала ял иткән.

Мәдәният кешеләрне берләштерә, үсеш векторын билгели, төп кыйммәтләрне формалаштыра, җәмгыятебезнең бөтенлеген тәэмин итә. Әлеге блокка күчеп, шуны билгеләп үтәсем килә: без ел дәвамында республика хөкүмәте, министрлыклары, муниципалитетлары һәм якын-тирә төбәкләр вәкилләре катнашында тиешле дәрәҗәдә чаралар оештырдык һәм уздырдык. Болар - Бөек Ватан сугышының 79 еллыгына багышланган парад, район Сабантуе, Оренбург өлкәсендә күрсәтмә Сабантуй, «Кымыз бәйрәме - Праздник кумыса» II төбәкара фестивале, октябрь аенда В.И. Ленин исемендәге мәдәни-ял итү комплексында «Татарстанның мәдәни башкаласы» конкурсы кысаларында Ютазы районы мәдәнияте көне үткәрелде.

Районның мәдәният учреждениеләре ел саен грант конкурсларында җиңү яулыйлар. 2024 елда 28 эш җибәрелгән, шуларның бишесенә ярдәм

күрсәтелде: - "Бергә бәхетле" проекты татар һәм рус мәдәни-ял итү мохитен булдыру конкурсында җиңүче булды (120 мең сум);

- Кәрәкәшле авыл китапханәсе Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Яшь буын китапханәсе» грантын алды - авыл китапханәсендә «ПЕРЕЗАГРУЗКА» яшьләр клубы оештыру (360 мең сум);

- Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территорияләрендәге иң яхшы муниципаль мәдәният учреждениеләре һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан акчалата бүләкләү конкурсында Байлар авыл мәдәният йорты һәм Подгорный мәдәният йорты мөдире Әхтәмова Ризидә Нусрат кызы җиңделәр (125 мең сум һәм 62,5 мең сум);

- Район мәдәният йорты хормейстеры Нигъмәтуллина Гүзәл Марсель кызы дәүләт һәм муниципаль мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант алу конкурсында җиңүче булды (70 000 сум);

- Тарих-туган якны өйрәнү музее Татнефть грантларының IV конкурсында җиңүче булды һәм экспозиция булдыру өчен 12 430 мең сум акча отты.

«Татнефть» ГАҖ җитәкчелегенә Маганов Наил Өлфәт улына социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашырганнары өчен рәхмәт белдерәм.

Солистлар һәм иҗат коллективлары ел дәвамында халыкара, төбәк һәм республика конкурсларында һәм фестивальләрендә актив катнаштылар.

«Пушкин картасы» федераль программасы кысаларында 441 чара үткәрелгән (2023 елда - 374), 4282 билет сатылган (2023 елда - 4447), гомуми суммасы 1 314 мең сум (2023 елда - 1 053,4 мең сум).

Мәдәният учреждениеләре объектларын ремонтлауга һәм җиһазландыруга аерым игътибар бирелә. Хисап елында җирле бюджет хисабына Салкын Чишмә авылындагы клубка капиталь ремонт ясалды, сәхнә киемнәре һәм тамаша залы өчен урындыклар сатып алынды, гомуми суммасы 3 млн.556 мең сум. Район китапханәләренә 459 мең сумлык алты мең данә китап кайтты.

Бүгенге көндә хакимият органнарының эшен яшьләргә таянмыйча күз алдына да китереп булмый.

Районда «Атлант» яшүсмерләр-яшьләр клубы бик актив эшли. Социаль франшиза алуга проектны уңышлы яклау агымдагы елның августында "Атлант" ПМК пространствосы базасында "Игелекле Ютазы" Игелек Үзәген ачарга мөмкинлек бирде. Һәм хәзер һәр кеше волонтер булырга, һөнәри ярдәм алырга мөмкин. Район территориясендә Җиңү волонтерлары, Без бергә отряд волонтерлары, Яшь Гвардия һәм «Игелекле Ютазы" отряды волонтерлары эшли.

Узган ел яшьләр сәясәте өлкәсендә иң көчле вакыйга «Дубравушка» балаларны савыктыру лагерен ачу булды, анда «Җәй – балаларга» республика программасы буенча ике торак корпус, медпункт, КПП, душ комплексы, склад төзелде, барлыгы 146 млн.сумга. Слайдта сез республика Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов эш визиты белән килгән

икенче сменаның матур кадрларын күрә аласыз. Ул балаларның яшәү шартларын һәм аларның ялын оештыруны бәяләде.

Районның барлык халкы өчен спорт белән шөгыльләнү өчен тигез мөмкинлекләр тудыру – җирле үзидарә органнарының төп бурычы.

Спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлырак шартлар тудыру өчен «Спорт объектларын капиталь ремонтлау» республика программасы буенча «Олимп» спорт комплексына 192 млн.сумлык капиталь ремонт ясалды.

Спорт мәктәбендә 10 спорт төре үсеш ала: спорт (грек-рим) көрәше, көрәш, баскетбол, футбол, хоккей, чаңгы ярышлары, гер спорты, җиңел атлетика, йөзү, өстәл теннисы бүлекләре, биредә 635 бала шөгыльләнә.

Республикада иң яхшы өчлеккә кергән «Шмель» картинг клубының гаять зур үсешен билгеләп үтәргә кирәк.

Районда уза торган массакүләм спорт чаралары бик популяр: чаңгы юлы-Татарстан 2024, барлык учреждение һәм предприятиеләрнең ГТО нормаларын тапшыру, Кросс - Татарстан 2024 барлык категория халыкны җыя, анда өч мең ярымнан артык кеше катнаша.

Физик культураны һәм спортны популярлаштыруга безнең спортчыларның нәтиҗәләре ярдәм итә:

- Солтанов Самат Кыргызстан Республикасының Чалпан-Ата шәһәрендә үткән гер спорты буенча дөнья чемпионатында үз авырлык категориясендә көмеш призер булды;
- Әгъзамова Арина бокс буенча Идел буе федераль округы беренчелегендә югары нәтиҗәләргә ирештеләр;
- Игонина Софья самбо буенча Бөтенроссия ярышларында алтын медаль иясе булды, ә апалы-сеңелле Арина һәм Элина Галиевалар Татарстан Республикасы чемпионатында спортның бу төре буенча 1 урынны алдылар.

Безнең сигез тәрбияләнүчебез Татарстан Республикасы җыелма командасында, Хожаков Җәлил грек-рим көрәше буенча Россия җыелма командасына керде.

Спорт һәм яшьләр сәясәте бүлегенә массакүләм спортны алга таба үстерү, спорт секцияләре эшен активлаштыру, аерым алганда, көрәш, футбол, хоккей буенча планнар эшләргә һәм гамәлгә ашырырга, ә теннис манежы ачылу уңаеннан безнең районда теннис үсешенә басым ясарга кирәк.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм өлкәннәр өчен адаптив спортны үстерүгә аерым игътибар бирүегезне сорыйм.

Хөрмәтле утырышта катнашучылар!

Соңгы елларда без халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуда сизелерлек нәтиҗәләргә ирештек. Хисап елында район объектларны төзү һәм капиталь ремонтлау буенча 28 республика һәм федераль программада, «Татнефть» ГАҖнең өч грантында катнашты, тармак буенча барлыгы 1 миллиард 6 миллион 291 мең сум үзләштерелгән, бу узган елга караганда 14% ка күбрәк. Эре төзелеш һәм капиталь ремонт объектлары буенча мин төп тармакларның эшчәнлеген бәяләгәндә хәбәр иттем, торак-коммуналь хуҗалык һәм юллар төзелеше өлкәсендә дә зур эш башкарылды.

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт программасы буенча 24 млн. 198 мең сумга алты йорт ремонтланган.

Республика программалары буенча Урыссу һәм Бәйрәкә торак пунктларында 3,6 км озынлыкта суүткәргеч төзелде, 21 млн.298 мең сумлык 51 күзәтү коесы урнаштырылды, Солнечный микрорайонында 4 млн. 832 мең сумлык канализация насос станциясе урнаштырылды.

Халыкның уңайлылыгын тәэмин итүдә региональ газлаштыру һәм догазификацияләү программасында катнашу мөмкинлеге зур әһәмияткә ия.

Хисап елында Подгорный һәм Бәйрәкә авылларындагы күпфатирлы йортларда 5 млн. 903 мең сумлык җылыту системасының индивидуаль казаннарын алыштырылды.

Догазификация программасы буенча 159 гариза бирелгән, 152 йорт тоташтырылган. Безнең район әлеге программа буенча республикада 1 нче урында тора.

«Татарстан Республикасы торак пунктларында урамнарны яктыртуны торгызу» программасы буенча район буенча 200 яктырткыч (2 млн.719 мең сум) алыштырылды һәм урнаштырылды.

Безнең район «Татнефть» ГАҖ грантларын бирү конкурсында актив катнашты. Бу акчаларга Ташкичү торак пунктында су белән тәэмин итү челтәре төзелде, Урыссу бистәсендә Тукай урамында яңа балалар мәйданчыгы урнаштырылды. Район үзәгендә Җиңү паркын төзекләндерү эшләре башланды.

Авыл җирлекләренә бирелгән грантлар һәм җирле бюджеттан финанслашу хисабына Акбаш һәм Бәйрәкәтамак авыл җирлекләре тракторлар сатып алдылар (4 млн.800 мең сумлык).

Авыл җирлекләре башлыкларын һәм бюджет учреждениеләре җитәкчеләрен грант ярдәме программаларында активрак катнашуларын сорыйм. Бу безнең район үсешенә өстәмә инвестицияләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Әбсәләм-Уба автоюлындагы юл өслегенең торышы турында халыктан күп мөрәҗәгатьләр килде. Узган елда республика программасы буенча әлеге кишәрлекне торгызу һәм яхшырту эшләре башкарылды.

Хисап елында юлларга капиталь ремонт ясауга 160 млн.сумнан артык акча юнәлдерелгән *(муниципаль юл фонды – 14,9 млн. сум, вак ташлы-комлы нигез салуга – 20 млн. сум, асфальт-бетон белән капланган юл – урам челтәрен ремонтлауга – 15 млн. сум, өстәмә юл фонды - 2,1 млн. сум. «Имин сыйфатлы юллар» милли проекты буенча Бөгелмә-Ютаза автомобиль юлын ремонтлау - 19 млн.сум, Әбсәләм-Уба автомобиль юлын ремонтлау - 92 млн. сум)*.

«Торак һәм шәһәр мохите» милли проекты кысаларында «Иске карьер» күлендә пляжны җиһазлау буенча өченче чиратны тәгалләдек. Төзекләндерелгән

территориядә Татарстан Республикасы Инвестиция советы тарафыннан хупланган "Мизгел Кэмп" Глэмпингын төзү" проектын гамәлгә ашыру планлаштырыла. Шул рәвешле район халкына һәм кунакларына ел әйләнәсе уңайлы ял итү өчен рекреацион инфраструктура булдырылачак. Моннан тыш, эшмәкәр пляжны карап тоту буенча йөкләмә алды.

Хөрмәтле депутатлар!

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре җәмгыятьтә кәефнең ачык һәм төгәл күрсәткече, хакимияткә ышаныч индикаторы булып тора. 2024 елда гражданнарның 509 мөрәҗәгате теркәлгән, «Инцидент-менеджмент» аша 936 хәбәр кергән. Гражданнарны шәхси кабул итү кысаларында 128 кеше кабул ителде. Искәртеп үтәм, мөрәҗәгатьләрнең күп өлеше социаль челтәрләр аша шәхси хәбәрләргә керә. Без аларга кыска вакыт эчендә җавап бирәбез.

Районның барлык авыл җирлекләрендә дә гражданнар җыеннары узды.

Хөрмәтле башлыклар һәм депутатлар, җитәкчеләр, сездән дә халык белән актив эш алып баруыгызны сорыйм. Ешрак очрашырга, аралашырга, халыкны нәрсә борчыганы турында белергә.

Хөрмәтле дуслар!

Безне бик җаваплы ел көтә. Иң мөһим бәйрәмне – Җиңүнең 80 еллыгын иң югары оештыру дәрәҗәсендә уздырырга кирәк. Безнең алда берничә мөһим бурыч тора: махсус хәрби операциядә катнашучы ир-егетләребезгә ярдәм итү, ветераннар, махсус операция инвалидлары һәм аларның гаиләләре, һәлак булган геройларның туганнары һәм якыннары белән эшләү, аларның истәлеген мәңгеләштерү, сугышчыларны һәм аларның туганнарын медицина тернәкләндерү, яшьләр белән хәрби-патриотик эшләү, районны үстерү планнарын һәм программаларын гамәлгә ашыру, икътисадны, социаль өлкәне ныгыту, инвестиция проектларын гамәлгә ашыру, кешеләрнең тормыш сыйфатын тагын да яхшырту. Һәр юнәлеш буенча конкрет бурычларга мин югарыда тукталдым.

Хөрмәтле коллегалар!

Россия Федерациясе Президентын сайлаулар елның мөһим сәяси вакыйгасы булды. Сентябрьдә республика Дәүләт Советының җиденче чакырылышы сайланды.

Гражданлык позицияләре һәм тавыш бирүдә актив катнашулары өчен район халкына рәхмәт белдерәм. Рәхмәт сезгә!

Агымдагы елның сентябрендә Татарстан Республикасы Рәисен, район Советы һәм авыл җирлекләре депутатларын сайлаулар булачак. Безнең бурыч - сайлауларны югары оештыру дәрәҗәсендә әзерләү һәм уздыру, сайлаучыларның килүен тәэмин итү.

Хөрмәтле Мидхәт Рәфкать улы, 2024 елда Татарстан Республикасы бюджеты хисабына күп эш башкарылды һәм бүген мин сезнең йөзегездә Рәисебез Рөстәм Нургали улы Миңнехановка, Дәүләт Советына, республика Министрлар Кабинетына, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә районыбызның инфраструктурасын үстерүдә, халкыбызның тормыш сыйфатын яхшыртуда һәрьяклап ярдәм иткәннәре өчен рәхмәт белдерәм.

Шулай ук барлык депутат корпусына, администрациянең структур бүлекчәләренә, авыл җирлекләре башлыкларына, җитәкчеләргә һәм коллективларга бердәм, актив эшчәнлекләре өчен рәхмәт белдерәм.

**Барыгызга да саулык-сәламәтлек, иминлек телим!**

**Игътибарыгыз өчен рәхмәт**

**Благодарю за внимание**